| | |
|---|---|
| ГЛАВА ЧУКМАРЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧУКМАРЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2024 ел, 5 ноябрь** **№ 4**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Нарат- Асты авылында 2025 елда үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге Уставының 18.1 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар кабул итте:

1. 2024 елның 19 ноябрендә 13.00 сәгатькә Сарман муниципаль районы, Нарат - Асты авылы, Нарат Асты урамы, 23 нче йорт адресы буенча урнашкан Нарат - Асты авылы медпункты бинасында, Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Нарат-Асты торак пунктында 2024 елда гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы? Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы авыл җирлегендә , I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан тыш, алынган акчалар җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә ризамы:

1) Нарат-Асты торак пунктында урамнарны яктырту җайланмасы (лампалар, энергияне саклый торган яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

2) Нарат - Асты торак пунктында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3)Нарат - Асты торак пунктында су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су җыю манарасын һәм су белән тәэмин итү системасын ремонтлау).

«ЭЙЕ» «Юк»?

3.Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы», муниципаль берэмлекнен рэсми сайтына, «Интернет мәгълүмат» теле коммуникация челтэрендэ, Чукмарлы жирлеге стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә,

4. Әлеге карар игълан ителгэн көннән үз көченә керә.

Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы

Сарман муниципаль районы И. Х.Хадиуллин